**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 13 апрель | № 217

г. Казань

Юридик затларның ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасыннан булган затларга мухсуслашкан торак урыннар наемы шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм Юридик затларның ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасыннан булган затларга мухсуслашкан торак урыннар наемы шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Юридик затларның ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасыннан булган затларга мухсуслашкан торак урыннар наемы шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 апрель, 217 нче карары белән расланды

# Юридик затларның ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасыннан булган затларга мухсуслашкан торак урыннар наемы шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм юридик затларның ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасыннан булган затларга мухсуслашкан торак урыннар наемы шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен билгели.

2. Субсидияләр ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасыннан булган затларга мухсуслашкан торак урыннар наемы шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга (фатирларга) (алга таба – торак урыннар) милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарны гамәлгә ашырган юридик затларга бирелә.

3. Субсидияләр әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованияләре һәм Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре кысаларында бирелә.

4. Субсидияләр оештыру-хокук формасына бәйсез рәвештә (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән гайре), түбәндәге шартларга җавап биргән юридик затларга бирелә:

законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган;

үзгәртеп төзү, бетү яки банкротлык стадиясендә булмаган;

элек бирелгән бюджет акчасын максатсыз һәм (яки) нәтиҗәсез файдаланмаган;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларына мәҗбүри түләүләр буенча кредит бурычлары булмаган.

5. Субсидия алу өчен юридик затлар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

торак урыннарның адресларын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан таныкланган һәм кредит оешмасы мөһере куелган торак урыннарга милек хокукын рәсмиләштерү буенча чыгымнарны раслый

торган түләү документлары күчермәләре;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларына мәҗбүри түләүләр буенча кредит бурычлары юклыкны раслый торган документ;

субсидия бирү турында гариза тапшырылган көнгә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә юридик затка карата бетерү, банкротлык, аның эшчәнлеген туктатып тору процедуралары булмау хакында юридик затның җитәкчесе имза куйган гарантия хаты;

юридик затны гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кергән барлык үзгәрешләр документлары күчермәләре;

җитәкче вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре.

6. Юридик затлар үз инициативалары белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

7. Юридик зат әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати бәйләнешләр тәртибендә соратып ала.

8. Министрлык субсидия бирү турында гаризаны теркәлгән документлары белән кергән көнендә кабул итә һәм терки.

9. Субсидия бирү яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында гариза кабул ителгән һәм теркәлгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ун көн эчендә кабул ителә.

Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәрнамәне Министрлык тиешле карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә язма рәвештә юридик затка җибәрә.

Юридик затка бирелә торган субсидия зурлыгы милек хокукын дәүләт теркәвенә алуы рәсмиләштерелгән торак урыннар саныннан һәм күчемсез мөлкәткә хокукны дәүләт теркәве өчен дәүләт пошлинасы зурлыгыннан чыгып билгеләнә.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар комплектын тулысынча тапшырмау;

тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

гариза бирүченең әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

Субсидия бирүдән баш тартылган очракта хәбәрнамәдә баш тартуның сәбәпләре күрсәтелә.

11. Субсидия бирү Министрлык һәм субсидия бирү турында карар кабул ителгән юридик зат (алга таба – субсидия алучы) арасында субсидия бирү турында килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Субсидия бирү турында килешү билгеләнгән тәртиптә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә төзелә.

Субсидия бирү турында килешү формасы Министрлык тарафыннан раслана.

Субсидия бирү турында килешүдә субсидиянең зурлыгы, аның максатчан билгеләнеше, субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешләрен субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары һәм тәртибе, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафынан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын саклавын тикшерүләр үткәрүгә субсидия алучының ризалыгы күздә тотыла.

12. Министрлык субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ун көн эчендә субсидияне субсидия алучының россия кредит оешмасында ачылган счетына күчерә.

13. Субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән ун көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру;

субсидия бирү шартларын үтәмәү;

субсидия акчасын максатчан файдаланмау.

14. Субсидия бирү турында килешүдә каралган очракларда хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыклары хисап елыннан соң килә торган айның 1 февраленә кадәр юридик зат тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытларын бозганда Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты үткәннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән акчаны мәҗбүриләп кире кайтарту чарасын күрә.

16. Субсидия максатчан характерда һәм башка максатларга файдаланыла алмый.

17. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Субсидия акчасын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүне министрлык гамәлгә ашыра.

19. Юридик затлар Министрлыкка тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап тота.

_______________________________